СОВЕТ ВЕРХНЕОШМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
с..Верхняя Ошма, д.54 а, с. Верхняя Ошма, Мамадышский район, Республика Татарстан, 422163

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЮГАРЫ УШМА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Совет ур., №54а нче йорт,ЮгарыУшма авылы, Мамадыш районы, Татарстан Республикасы,422163

тел.(факс): (85563) 2-32-36; e-mail: Voshm.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Карар
02 нче октябрь 2017 ел

Решение
№ 1-24

**Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм аларны куллану буенча җирле референдум үткәрү көнен билгеләү турында**

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларынын һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 ел, 12 июнь, 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясының 2 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 ел, 6 октябрь, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, "Жирле референдум турында» 2004 ел, 23 март, 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Югары Ушма авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясы, Югары Ушма авыл җирлеге башкарма комитетының “Референдум уздыру инициативасы турында” 2017 нче елның 20 че сентябрендә кабул ителгән 14 нче номерлы карары, Югары Ушма авыл жирлеге Советының “Референдум уздыру инициативасы турында” 2017 нче елның 20 нче сентябрендә кабул ителгән 3-23 нче номерлы карары, Югары Ушма авыл җирлеге Советынын “Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Югары Ушма авыл җирлегендә гражданнардан узара салым акчасын җыю һәм куллану кагыйдәләре” 2014 нче елның 2 нче апрелендә кабул ителгән 2-35 нче номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлеге Советы К А Р А Р КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм аларны куллану буенча жирле референдум үткәрү көнен 2017 нче елның 19 нче ноябренә билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2018 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертелүгә

һәм ул акчаларны жирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

1. Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә беренчел пожар куркынычсызлыгын тәэмин итү чараларын булдыру :

Пожар гидрантларын сатып алу һәм урнаштыру:

- Алкин торак пунктында, Хәсәншә торак пунктында, Комазан Урмачылыгы торак пунктында.

2. Авыл жирлеге торак пунктларында су белән тәэмин итү:

Югары Ушма торак пунктында су алу башнясын әйләндереп алу

Комазан Урманчылыгы торак пунктында су алу башнясына ремонт эшләре үткәрү

3.Җирлекнен торак пункт чикләрендә жирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

Югары Ушма торак пунктында Чапай,Мухамадиев урамында,Ак Чишмә торак пунктында К.Маркс урамында юлны вакташ җәеп ремонтлау.

4. Ритуал хезмәтләрен оештыру һәм жирләү урыннарын саклау:

Иске Завод торак пунктында зиратны койма белән әйләндереп алу.

5. Торак пункт территориясен төзекләндерүне оештыру:

Хәсәнша торак пунктында чишмәне төзекләндерү.

« ӘЙЕ » « ЮК »

4. Әлеге карарны муниципаль берәмлек Советының мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлеге башлыгы М.Р.Хузязяновка йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Олыяз авыл жирлеге башлыгы,
Совет председателе /М.Р.Хузязянов/